**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**13.09.2019** **№ 1544**

# 2019-2020 уку елында Биектау муниципаль районы мәгариф оешмалары укучыларының кайнар ризык белән туклануын оештыру турында

“Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы, “Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта профессиональ белем бирү учреждениеләрендә белем алучыларның туклануын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр” СанПиН 2.4.5.2409-08, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2019 нчы елга айлык акчалата түләүләр һәм башка төрле түләүләр турындагы” 2017 елның 10 сентябрендәге 767 номерлы Карарны үтәү максатыннан, шулай ук балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлекләрен ныгыту, Биектау муниципаль районы мәгариф оешмаларында белем алучыларны кайнар ризык белән тәэмин итү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 нчы елның 1 нче сентябреннән 2020 елның 31 нче маена кадәр Биектау муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештырырга.

Гомуми белем бирү оешмаларында белем алучыларны туклandыру өчен каралган чыгымнарны финанслау өчен акчаларны түбәндәгечә юнәледерергә:

- гомуми белем бирү оешмаларында белем алучыга бер көн өчен республика бюджетыннан ай саен түләнелә торган акчалата түләүләр – уку елының беренче яртыеллыгы өчен 7 сум 40 тиен хисабыннан;
- гомуми белем бирү оешмаларының бюджеттан тыш чаралары;
- әти- әниләрнең (законлы вәкил) ирекле түләүләре;
- күп балалы гаиләләрдән булган укучылар өчен җирле бюджеттан көненә 15,0 сум.

2. Мәгариф учреждениеләренә укучыларның туклануын оештыру буенча эшчәнлекне “Казан шәһәре азык-төлек һәм социаль туклану Департаменты” АЖ белән дәвам итүне киңәш итәргә.

3. Гамәлдә булган законнар нигезендә, укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүне оештыру өчен җаваплылыкны гомуми белем бирү оешмаларының җитәкчеләренә йөкләргә.

4. Татарстан Республикасы буенча “Роспотребнадзор” идарәсенең Арча, Биектау районнарындагы (Арча ТОсы) территориаль бүлегенә (Салкова Э.В.) районның гомуми белем бирү оешмаларында белем алучыларның туклануын оештыру өчен тәэмин итүчеләр тарафыннан китерелгән продуктларның сыйфатын даими тикшереп торуны, мөстәкыйль рәвештә укучыларның туклануын оештыручы оешмаларда гамәлдәге законнар нигезендә туклануны оештыруга тулы күләмдә җитештерү контролен (лаборатор контрольне дә кертеп) тормышка ашыруны тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасына район бюджетыннан укучыларны тукландыру өчен каралган максатчан кулланылырга тиешле чараларны Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф бүлеге” МКУ сметасы буенча билгеләнгән нормативлар нигезендә үз вакытында күчүне тәэмин итәргә.

6. “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф бүлеге” МКУсы (Әхмәтҗанов Н.К.), Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасы (Вәлиуллина Р.Ш.) кайнар ризык белән тәэмин итү, акчаларның хисабын алу, мәктәп яны кишәрлекләрендә җитештерелгән продукция хисабына мәктәптәге төшке ашларның рационын һәм ассортиментын баету буенча бүлеп бирелгән акчаларның акчаларның максатчан тотылуын тәэмин итәргә.

7. Карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча урнашытырып халыкка җиткерергә.

8. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесенең урынбасары - “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф бүлеге” МКУ начальнигы Әхмәтҗанов Н.К.ка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин